ГЛАВА УРУССИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с. Старые Уруссу, ул. Советская,
д.16в, 423960

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Иске Урыссу авылы, Совет урамы,
16в йорт, 423960

Тел.: (85593) 4-42-31, факс: 4-41-52, e-mail: Uruss.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

N 1 10 ноябрь 2023 ел

2024 елда Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 7 санлы карары белән кабул ителгән Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Уставының 14, 81 маддәләренә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советының 2019 елның 28 октябрендәге 14 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында»гы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Урыссу авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елның 21 ноябрендә 17.00 сәгатькә Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Иске Урыссу торак пункты, Совет урамы, 45А йорт адресы буенча урнашкан Иске Урыссу авыл мәдәният бинасында, 2024 елда Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, Бөек Ватан сугышында катнашучы тол калган хатыннардан тыш, 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә сез ризамы:

- Иске Урыссу торак пунктында Елга урамы, 1 Май урамы буенча юлларны норматив хәлгә китерү (төзү, реконструкцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак таш җәю, төзелеш материаллары сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Хәтер скверы территориясенә хезмәт күрсәтү (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- авыл эчендәге юлларны карап тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- зиратта хуҗалык инвентары өчен бина төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- милли Сабантуй бәйрәмен үткәрү урынын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Урыссу авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, кабул ителгәннән соң 5 көн дәвамында Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://yutaza.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (peep//pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Әминова